# Г. Ибраһимов әсәрләрендә атау җөмләләр

**Г.Ә. Нәбиуллина, КДУ**

Г. Ибраһимов, әдәби яктан милли прозаның идея-тематик колачын киңәйтеп, аңа яңа сулыш бирсә, икенче яктан әдәби телне яңадан-яңа сурәтләү чаралары, поэтик-синтаксик алымнар, стилистик фигуралар белән баетып, татар теленең мөмкинлекләрен, байлыгын проза өлкәсендә яңа биеклеккә күтәрә.

Г. Ибраһимов прозасына хас аһәңлелек, камиллек, нәфислек, лиризм һәм романтик рух иң беренче чиратта, язучының хикәяләү осталыгына бәйле.  Г. Ибраһимовның теле, әсәрләренең тел-стиль үзенчәлекләре, әдип буларак осталыгы турында фәнни әдәбиятта күп язылды. Безнең максат Г. Ибраһимов әсәрләренең структур-синтаксик оешуында, пейзаж, портрет микоротекстларының формалашуында мөһим роль уйнаган атау җөмләләрнең кулланылыш үзенчәлекләрен ачарга омтылыш ясаудан гыйбарәт.

Г. Ибраһимов әсәрләрендә бер составлы җөмләләрнең гаять бай структур-семантик төрләре кулланыла. Язучы атау җөмләләр, бер составлы фигыль, сүз җөмләләрнең стилистик  мөмкинлекләрен гаять урынлы файдалана.

Г. Ибраһимов әсәрләрендә пейзаж, портрет, психологизм микротекстлары еш кына номинатив җөмләләлардән торган хикәяләү нигезендә туа. Язучы номинатив җөмләләрне аеруча пейзаж тасвирлауда яратып куллана. Мәсәлән, Җылы яңгыр. Якты кояш. Ни күрим: бер атнадан матур сабаклар, яшел яфраклар чыкты; җәй көне аллы-гөлле кызыл чәчәкләр бөтен бакчама яшь бирде; көз көне энҗе-мәрҗән бөртекләре кебек тигез, матур кызыл орлыклар җыеп алдым. ( Г. И. 6, 9). Караңгы, дөнья тын. Ләкин диңгез шаулый. Диңгез төбендә *кемгәдер ачу белән үкеренә. Аның куәтле дулкыннары тау-тау булып биек, ташлы,*

*текә ярларга һөҗүм итәләр (Г.И. 5, 89 б.).* Күренгәнчә, пейзаж текстының атау җөмләләр белән башланып китүе әсәргә тәэсирле башлангыч бирәләр. Бу төр башлам җөмләләрдә төп мәгънә туплана, аны артыннан килгән җөмләләр атау җөмләләрдә бирелгән фикерне, күренешне, төрле яклап ачыклыйлар.

Г. Ибраһимов әсәрләрендә урын алган атау җөмләләр сурәт, образ тудыралар, предмет-күренешләрне атыйлар, хикәяләүгә яңа күренешләр, затлар, предметлар кертәләр. Номинатив җөмләләр хис-тойгылар, эмоцияләр белән үрелеп баралар, хикәяләүне җанландырып, аны тагын да ачыграк итәләр, сурәтләргә, төсләргә баеталар.

Автор билгеле бер обстановканы төгәл, җыйнак, аһәңле итеп укучыга җиткерүдә дә еш кына атау җөмләләрдән файдалана. Обстановканы нечкәлек белән тасвирлауда номинатив җөмләләр еш кына *әнә, менә* сүзләре белән баетыла. Мәсәлән, *Менә нинди әйбәт ак бина... Көндезге кояш вакытында аның эче җылы йомшак нур белән тула...(Г.И. 5, 179). Әнә урамга ике яклап тезелгән кечкенә авыл... Менә салам түбәле өйләр... Әнә капка төбендә куелган урак машинасы канатларын күтәреп тора (Г. И.6, 150).* Биредә *әнә, менә* сүзләре төбәп әйтү, күрсәтү төсмере өстиләр. Автор, әйтерсең, шушы моментта күз алдында тотылган, каршыда булган предмет-күренешләрне күрсәтеп сөйли.

Г. Ибраһимов геройларның портретын тасвирлауда, һәркайсын кабатланмас итеп сурәтләүдә атау җөмләләр чылбырыннан файдалана. Портретны бөтен барлыгын, тулылыгын нечкәләп, детальләп сурәтләүдә әһәмиятле күренешне ассызыклауда атау җөмләләр уңышлы файдаланыла. Атау җөмләләрнең кыска, җыйнак булуы мәгънәне тыгыз итеп бирергә ярдәм итә, сөйләмне, хикәяләүне бизәкләргә, төсләргә баета. *Кыска буйлы, ябык гәүдәле, кәҗә сакаллы, азрак кылый күзле бер карт иде. Өстендә иске җилән, аны билдән буган. Башында чите камалы мескен бүрек, аягында оек-чабата (Г. И, 8,166); Аягыда зур итек.*

*Өстендә кара чикмән. Башында кара эшләпә. Кулында ике телле шәп гармун. Менә Шәйхел шулай юньсезләнеп кайтып төште (Г. И., 5, 58). Ябык, чандыр гәүдәле, эчке хәйләкәр күзле, җиңел кузгалышлы бер карт иде. Ияге очланып килгән, яңак сөякләренең югары ягы тышка бәреп тора, берничә бөртек чал сакалы җемелди. Үзе ничек җитез (Г. И. 6, 331).* Күренгәнчә, тулы бер абзац атау җөмләләр чылбырыннан тора. Сегментланган кисәкләр, аерым сүз-сурәтләр аша укучының күз алдына тирән мәгънә, образ, хәрәкәт килеп баса. Портретны сурәтләүче атау җөмләләр укучының фикерләү, күзаллау сәләтен арттыралар, төсләргә, фантазиягә баеталар.

Атау җөмләләр, составында бәяләү төсмерен белдерүче *нинди, ничаклы*, *шулкадәр* сүзләре килеп, психологик портрет тудыруга хезмәт итәләр. Мәсәлән, *Караңгылана. Тирә-якта тын. Шулкадәр рәхәт! (Г.И. 6, 67); Күтәрелеп, диңгезгә бер каравым белән, күңелем ачылып, җаным канатланыпук ките. Йа ходам! Һава ни дәрәҗәдә саф! Ничаклы матурлык!* (Г. И. 5. 96б). Табигатьнең аерым күренешләре детальләп сурәтләнә. Мондый җөмләләр геройның рухи халәтен, эмоциональ кичерешләрен, тойгы белдерү чарасына әвереләләр, табигать күренешләре аша психологизм тудырыла.

**Чыганак**

1. Ибраһимов Г. Әсәрләр. Сигез томда. Т.1 / Г.Ибраһимов — Казан: Таткитнәшр., 1974. — 507 б.

2. Ибраһимов Г. Әсәрләр. Сигез томда. Т.2 / Г.Ибраһимов — Казан: Таткитнәшр., 1975. — 476 б.

3. Ибраһимов Г. Әсәрләр. Сигез томда. Т.3 / Г.Ибраһимов — Казан: Таткитнәшр., 1975. — 450 б.